СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**« 26 » октябрь 2015 ел** **№ 11**

**Арча муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 10-ФЗ номерлы Федераль законга, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2015 елның 22 гыйнварындагы 313 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

а) 16 статьяның 5 өлешендә «ачык сессия» сүзләрен «ачык утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

б) 21 статьяның 4 өлешендәге 3 абзацында «үзенең якындагы сессиясендә» сүзләрен «үзенең якындагы утырышында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 29 статьяның 2 өлешендә «беренче сессия» сүзләрен «беренче утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

г) 32 статьяда:

- 1 өлештә «беренче сессия» сүзләрен «беренче утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

- “Сайлаулардан соң беренче сессия” сүзләрен «сайлаулардан соң беренче утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

д) 34 статьяның 6 өлешендә «сессия» сүзләрен «утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

е) 42 статьяда:

- 2 п.п.«сессия» сүзләрен «утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

- 8 п.п. пунктында «сессия» сүзләрен «утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 53 статьяның 7 өлешендә «сессия» сүзләрен «утырыш» сүзләренә алмаштырырга;

з) 73 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район Советы карарлары, законнарда, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарларын кабул иткәндә муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.».

и) 82 статьяга түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18. Җирле бюджет проекты, җирле бюджетны раслау турындагы карар, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, җирле бюджетны үтәү барышы һәм җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең саны турында квартал саен бирелә торган белешмәләр, аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнарны күрсәтеп, рәсми басылып чыгарга тиеш.».

к) 89 статьяның 4 өлешендә «сессия» сүзләрен «утырыш» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны, ул кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә, Уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.

3. Арча муниципаль районы башлыгына уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органы Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән “Арча муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карарны бастырып чыгарырга.

4. Арча муниципаль районы башлыгына уставларны теркәү өлкәсендәге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына үзгәрешләр һәм өстәмәләр рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән соң 10 көн эчендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр чыганагы турында белешмәләр җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының Законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе

И.Г. Нуриев